| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2016 ел Казан ш. № 10-57/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 16 декабрендәге «2016 елга эчә торган суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортлауга һәм җыентык суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында»гы 10-40/кс номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2011 елның 7 декабрендәге «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 416-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 маендагы «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 406 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең 2013 елның 27 декбарендәге «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 1746-э номерлы боерыгына туры китереп, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 16 декабрендәге «2016 елга эчә торган суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортлауга һәм җыентык суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында»гы 10-40/кс номерлы карарының кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

21 пунктта:

21.1 пунктчасының дүртенче баганасында «19,61» саннарын «20,35» саннарына алмаштырырга;

21.2 пунктчасының дүртенче баганасында «16,62» саннарын «17,25» саннарына алмаштырырга;

21.1 пунктчасының сигезенче баганасында «12,99» саннарын «13,53» саннарына алмаштырырга;

21.2 пунктчасының сигезенче баганасында «11,01» саннарын «11,47» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 16 декабрендәге «2016 елга эчә торган суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны

транспортлауга һәм җыентык суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында»гы 10-40/кс номерлы карарына булган кушымтаның 21 пунктында билгеләнгән тарифлар шушы карар үз көченә кергән вакыттан башлап 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов